# КАРАР

**24 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге Студеный Ключ авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге Студеный Ключ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; локаль сугышларда һәм Украинада махсус операция барышында һәлак булганнарның гаиләләреннән; 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- чишмәләрне төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү;
- Студеный Ключ авылында сууткәргеч челтәрләрен һәм су белән тәэмин итү системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны, су саклау зоналарын ремонтлау, төзү, проектлау, карап тоту, төзекләндерү, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Студеный Ключ авылына янгын гидрантларын сатып алу, ремонтлау һәм урнаштыру,
шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, инвентарь һәм җиһазлар белән комплектлау;
- Студеный Ключ авылында зират территориясен карап тоту, ремонтлау, сатып алу һәм төзекләндерү һәм зиратны койма белән әйләндереп алу, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Студеный Ключ авылында балалар уен, спорт мәйданчыгы территориясен карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Студеный Ключ авылының гомуми файдаланудагы юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Студеный Ключ авылында урам яктырту челтәрләрен карап тоту, ремонтлау, сатып алу, урнаштыру, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- тракторны тоту (смета һәм документлар өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, комплектлау материаллары, аларга запас частьләр сатып алу, тракторчы хезмәте);
- Студеный Ключ авылында кышкы-җәйге чорда урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Студеный Ключ авылының яр буе зоналарын, сулыкларын чистарту;
- Студеный Ключ авылында җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргеч күперләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау, төзү, карап тоту, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 46 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 25 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 25 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Студеный Ключ авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: 1) «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге Студеный Ключ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокль хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; локаль сугышларда һәм Украинада махсус операция барышында һәлак булганнарның гаиләләреннән; 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- чишмәләрне төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү;

- Студеный Ключ авылында сууткәргеч челтәрләрен һәм су белән тәэмин итү системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны, су саклау зоналарын ремонтлау, төзү, проектлау, карап тоту, төзекләндерү, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Студеный Ключ авылына янгын гидрантларын сатып алу, ремонтлау һәм урнаштыру,
шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, инвентарь һәм җиһазлар белән комплектлау;
- Студеный Ключ авылында зират территориясен карап тоту, ремонтлау, сатып алу һәм төзекләндерү һәм зиратны койма белән әйләндереп алу, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Студеный Ключ авылында балалар уен, спорт мәйданчыгы территориясен карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Студеный Ключ авылының гомуми файдаланудагы юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Студеный Ключ авылында урам яктырту челтәрләрен карап тоту, ремонтлау, сатып алу, урнаштыру, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- тракторны тоту (смета һәм документлар өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, комплектлау материаллары, аларга запас частьләр сатып алу, тракторчы хезмәте);
- Студеный Ключ авылында кышкы-җәйге чорда урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, комплектлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Студеный Ключ авылының яр буе зоналарын, сулыкларын чистарту;
- Студеный Ключ авылында җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргеч күперләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау, төзү, карап тоту, шул исәптән проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урта Комар авыл җирлеге башлыгы С.В. Федоров

ОГРН 1021607752891
ИНН 1623001660